| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«УРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 19 октябре № 21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктны төшереп калдырырга;

б) 17 статьяның 1 өлешенең 1 пунктында «шәһәр» сүзен «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

в) 17 статьяның 1 өлешенең 10 пунктында «ел саен хисап финанс елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш» сүзләрен «тапшырырга» сүзенә алмаштырырга;

г) 17 статьяның 2 өлешендә «шәһәр» сүзен «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авылы, Үзәк урам, 4, Яңа Елховой авылы, Чишмәле урамы, 2, Бохар авылы Авангард урамы, 23 адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

.Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Ф.Хәбибуллин